МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.12.2024 Казан ш. № 02-109

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 25.12.2023 ел, № 02-144 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына карый торган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турындагы күрсәтмәләргә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 25.12.2023 ел, № 02-144 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына карый торган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турындагы күрсәтмәләргә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 24.07.2024 ел, № 02-60 боерыгы белән расланган үзгәрешләр нигезендә) кертелә торган үзгәрешләрне (кушымта итеп бирелә) расларга.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
02. 12.2024 года
№ 02-109

боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 25.12.2023 ел, № 02-144 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына карый торган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турындагы күрсәтмәләргә кертелә торган үзгәрешләр

1. «Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнары исемлеге һәм аларны тиешле максатчан статьяларга кертү кагыйдәләре» 2 пунктта:

а) «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.1. пунктчасында:

«01 2 13 00000 «Шикәр чиренә каршы көрәш» төбәк проекты» максатчан статьясында:

«- R1060 «2 яшьтән алып 4 яшькә кадәрге 1 типтагы шикәр чиреннән интегүче балаларны глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыруга финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- R1060 2 яшьтән алып 4 яшькә кадәрге 1 типтагы шикәр чиреннән интегүче балаларны глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча 2 яшьтән алып 4 яшькә кадәрге 1 типтагы шикәр чиреннән интегүче балаларны глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка субсидияләр» 000 2 02 29999 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

«- R1070 4 яшьтән 17 яшькә кадәрге 1 типтагы шикәр чиреннән интегүче балаларны глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыруга финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- R1070 4 яшьтән 17 яшькә кадәрге 1 типтагы шикәр чиреннән интегүче балаларны глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча 4 яшьтән 17 яшькә кадәрге 1 типтагы шикәр чиреннән интегүче балаларны глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка субсидияләр» 000 2 02 29999 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

түбәндәге чыгымнар юнәлешләрен өстәргә:

«- R1510 Авыл халкына һәм ерак территорияләрдә яшәүчеләргә медицина ярдәме күрсәтә торган медицина оешмаларын шикәр чирен ачыклау һәм элек ачыкланган шикәр чиреннән интегүче пациентның хәлен тикшереп тору өчен җиһазландыру (яңадан җиһазландыру) чараларын гамәлгә ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча авыл халкына һәм ерак территорияләрдә яшәүчеләргә медицина ярдәме күрсәтә торган медицина оешмаларын шикәр чирен ачыклау һәм элек ачыкланган шикәр чиреннән интегүче пациентның хәлен тикшереп тору өчен җиһазландыру (яңадан җиһазландыру) чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка субсидияләр» 000 2 02 29999 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

- R1520 Йөкле хатын-кызларны глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча йөкле хатын-кызларны глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка субсидияләр» 000 2 02 29999 02 0000 150 «керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

«01 4 12 00000 «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, аның карамагындагы оешмалар эшчәнлеген тәэмин итү, сәламәтлек саклау өлкәсендәге башка чаралар « процесслы чаралар комплексы» максатчан статьясында:

«- 05390 Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә иминләштерелгән затларга Татарстан Республикасы медицина оешмалары тарафыннан күрсәтелгән медицина ярдәме» чыгымнар статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 05390 Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә иминләштерелгән затларга Татарстан Республикасы медицина оешмалары тарафыннан күрсәтелгән медицина ярдәме»;

түбәндәге эчтәлектәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- R3870 Генетик эксперт тикшеренүләрен уздыруны федераль бюджет акчалары исәбеннән финанс белән тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча генетик эксперт тикшеренүләрен уздыруны федераль бюджет акчалары исәбеннән финанс белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертларның керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар» 000 2 02 49999 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

б) «Татарстан Республикасында мәгариф һәм фәнне үстерү» дәүләт программасы» 2.2. пунктчасында:

атамасында «Татарстан Республикасында мәгариф һәм фәнне үстерү» сүзләрен «Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү» сүзләренә алмаштырырга;

беренче абзацында «Татарстан Республикасында мәгариф һәм фәнне үстерү» сүзләрен «Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү» сүзләренә алмаштырырга»;

«02 0 00 00000 Татарстан Республикасында мәгариф һәм фәнне үстерү» дәүләт программасы» максатчан статьясында:

атамасында «Татарстан Республикасында мәгариф һәм фәнне үстерү» сүзләрен «Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү» сүзләренә алмаштырырга;

беренче абзацында «Татарстан Республикасында мәгариф һәм фәнне үстерү» сүзләрен «Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү» сүзләренә алмаштырырга»;

«02 4 01 00000 «Мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирүнең заманча механизмнары һәм технологияләре» процесс чаралары комплексы» максатчан статьясында түбәндәге чыгымнар юнәлешләрен өстәргә:

«- R0500 Татарстан Республикасы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларының, һөнәри белем бирү оешмаларының, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының балалар иҗтимагый берләшмәләре белән тәрбия һәм үзара хезмәттәшлек буенча директорлар киңәшчеләренә федераль бюджет акчалары исәбеннән ай саен акчалата түләү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларының, һөнәри белем бирү оешмаларының, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының балалар иҗтимагый берләшмәләре белән тәрбия һәм үзара хезмәттәшлек буенча директорлар киңәшчеләренә федераль бюджет акчалары исәбеннән ай саен акчалата түләүгә федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектларының, Байконур шәһәренең һәм «Сириус» федераль территориясенең дәүләт гомуми белем бирү оешмаларының, һөнәри белем бирү оешмаларының, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының һәм һөнәри белем бирү оешмаларының балалар иҗтимагый берләшмәләре белән тәрбия һәм үзара хезмәттәшлек буенча директорлар киңәшчелләренә ай саен акчалата түләүне тәэмин итүгә бюджетларга тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 45050 00 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

- R0501 Татарстан Республикасы муниципаль мәгариф оешмаларының тәрбия һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлек буенча директорлар киңәшчеләренә айлык акчалата түләү

- R0502 Татарстан Республикасы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларының, һөнәри белем бирү оешмаларының балалар иҗтимагый берләшмәләре белән тәрбия һәм үзара хезмәттәшлек буенча директорлар киңәшчеләренә айлык акчалата түләү

- R3030 Гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән айлык акчалата түләү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләүгә федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Башлангыч гомуми белемнең мәгариф программаларын, төп гомуми белемнең мәгариф программаларын, урта гомуми белемнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен

айлык акчалата түләүгә бюджетларга тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 45303 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.

- R3031 Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында гомуми һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү – муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагог хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләүләрне тәэмин итү өлешендә

- R3032 Гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләү»;

«02 4 03 00000 «Һөнәри белемне һәм өстәмә һөнәри белемне үстерү» процесс чаралары комплексы» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- R3630 Урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге (кураторлык) өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән айлык акчалата түләү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча урта һөнәри белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге (кураторлыгы) өчен айлык акчалата түләүгә федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары һәм Байконур шәһәре дәүләт мәгариф оешмаларының, урта һөнәри белем бирү уку-укыту программаларын, шул исәптән физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге (кураторлык) өчен айлык акчалата түләүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 45363 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

«02 4 04 00000 «Белем бирү сыйфаты системасын үстерү» процесс чаралары комплексы» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- 43700 Физика-математика белеменең сыйфатын яхшырту чаралары комплексын гамәлгә ашыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча физика-математика белеменең сыйфатын яхшырту чаралары комплексын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«02 4 06 00000 «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен психологик-педагогик медицина-социаль үзәкләр һәм дәүләт учреждениеләре

челтәре эшчәнлеген тәэмин итү» процесс чаралары комплексы» максатчан статьясы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«02 4 06 00000 «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен психологик-педагогик һәм медицина-социаль үзәкләр һәм дәүләт учреждениеләре челтәре эшчәнлеген тәэмин итү» процесс чаралары комплексы»;

в) «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.3. пунктчасында:

«03 4 01 00000 «Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү» процесс чаралары комплексы» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- 60830 Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кергән затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган һәм 23 яшькә җиткән затларга төзекләндерелгән торак урынны милеккә сатып алуга яисә торак урын сатып алуга бирелгән кредитны (займны) заем алучының йөкләмәләре ипотека белән тәэмин ителгән Шартнамә буенча тулысынча түләп бетерү өчен түләүләр бирү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кергән затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган һәм 23 яшькә җиткән затларга төзекләндерелгән торак урынны милеккә сатып алуга яисә торак урын сатып алуга бирелгән кредитны (займны) заем алучының йөкләмәләре ипотека белән тәэмин ителгән Шартнамә буенча тулысынча түләп бетерү өчен түләүләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«03 4 03 00000 «Гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү» процесс чаралары комплексы» максатчан статьясында

«- 66940 Украина территориясендә, шулай ук торак урыннарыннан китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасында вакытлыча урнашу һәм туклану пунктларында урнашкан (булган) Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын, чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыруга һәм тукландыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау)» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 66940 Украина территориясендә, шулай ук максималь һәм уртача хәвефлелек кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәүче, торак урыннарыннан китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасында вакытлыча урнашу һәм туклану пунктларында урнашкан (булган) Россия Федерациясе гражданнарын, чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыруга һәм тукландыруга бәйле чыгымнарны каплау»;

«03 4 04 00000 «Халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын арттыру» процесс чаралары комплексы» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- 05089 Тормышта авыр хәлләрдә калган балаларга ярдәм күрсәтү чаралары комплексын гамәлгә ашыру»;

г) «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү « Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.4. пунктчасында:

«04 2 06 00000 «Татарстан Республикасында ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны торак урыннары белән тәэмин итү « төбәк проекты» максатчан статьясында «- 60830 Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кергән затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган һәм 23 яшькә җиткән затларга төзекләндерелгән торак урынны милеккә сатып алуга яисә торак урын сатып алуга бирелгән кредитны (займны) заем алучының йөкләмәләре ипотека белән тәэмин ителгән Шартнамә буенча тулысынча түләп бетерү өчен түләүләр бирү» чыгымнар юнәлешен төшереп калдырырга;

«04 2 0К 00000 «Социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» төбәк проектын» максатчан статьясына чыгымнарның түбәндәге юнәлешен өстәргә:

«- R688F «Новая Портовая» гидротехник корылмасын төзү» Казан шәһәре, (1 этап) 1.1. этап» объектын гамәлгә ашыру максатларында финанслашыла торган чыгымнар, шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды акчалары хисабына

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Новая Портовая» гидротехник корылмасын төзү» Казан шәһәре, (1 этап) 1.1. этап» объектын гамәлгә ашыру максатларында федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка субсидияләр» 000 2 02 29999 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

д) «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.5. пунктчасында «05 4 01 00000 «Халыкны эш белән тәэмин итүнең актив сәясәте һәм эшсез гражданнарга социаль ярдәм» процессы чаралар комплексы» максатчан статьясында «- 52900 Эшсез гражданнарга федераль бюджет акчалары исәбеннән социаль түләүләр» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 52900 Эшсез гражданнарга һәм гражданнарның башка категорияләренә халыкның мәшгульлеге турындагы законнар нигезендә федераль бюджет акчалары исәбеннән социаль түләүләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча эшсез гражданнарга һәм гражданнарның башка категроияләренә халыкның мәшгульлеге турындагы законнар нигезендә социаль түләүләрне гамәлгә ашыру өчен федераль бюджет субвенцияләре хисабына башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субвенцияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына кертү бюджетлар керемнәре классификациясенең «Эшсез гражданнарга һәм гражданнарның башка категорияләренә халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнар нигезендә социаль түләүләргә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субвенцияләр» 000 2 02 35290 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

е) «Татарстан Республикасында су объектларында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү « Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.7. пунктчасына түбәндәге максатчан статьяларны өстәргә:

«07 2 00 00000 Федераль (төбәк) проектлары

07 2 0К 00000 «Социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» төбәк проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча төбәк проектын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 72310 Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкендәге социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт»;

ж). «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.8 пунктчасында «08 2 А1 00000 «Мәдәни мохит» федераль проекты» максатчан статьясына чыгымнарның түбәндәге юнәлешләрен өстәргә:

«- 54562 Төбәк һәм муниципаль Яшь тамашачы театрларын һәм курчак театрларын реконструкцияләү юлы белән модернизацияләү

- 55800 Төбәк һәм муниципаль театрларны реконструкцияләүгә һәм капиталь ремонтлауга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча төбәк һәм муниципаль театрларны реконструкцияләүгә һәм капиталь ремонтлауга федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Төбәк һәм муниципаль театрларны реконструкцияләүгә һәм капиталь ремонтлауга бюджетларга субсидияләр» 000 2 02 25580 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

з) «Татарстан Республикасын икътисадый үстерү һәм инновацион икътисад» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.10 пунктчасында «11 2 06 00000 «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү» төбәк проекты» максатчан статьясында направление расходов «- 6527А «Татарстан

Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм итү фонды» коммерциясез микрокредит компаниясенең «Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан экспортка ярдәм итү үзәкләре ярдәмендә товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) экспортын гамәлгә ашыру «чарасын гамәлгә ашыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидияләр» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 6527А «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм итү фонды» коммерциясез микрокредит компаниясенең «Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан экспортка ярдәм үзәкләре ярдәмендә товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) экспортын гамәлгә ашыру» чарасын гамәлгә ашыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидияләр»;

и) «Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.12. пунктчасында:

түбәндәге максатчан статьяны өстәргә:

«13 2 06 00000 «Төбәк аэропортларын үстерү»
төбәк проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча төбәк проектын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 72360 Аэропорт комплексларында объектларны реконструкцияләү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча аэропорт комплексларында объектларны реконструкцияләүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«13 2 R1 00000 «Төбәк һәм җирле юл челтәре» Федераль проекты» максатчан статьясына чыгымнарның түбәндәге юнәлешен өстәргә:

«- 5394F Автомобиль юлларын һәм ясалма юл корылмаларын норматив хәлгә китерүгә, шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды акчалары исәбеннән, финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча автомобиль юлларын һәм ясалма юл корылмаларын норматив хәлгә китерүгә федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясендәге «Автомобиль юлларын һәм ясалма юл корылмаларын норматив хәлгә китерүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25394 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

«13 2 V7 00000 «Төбәк аэропортларны үстерү» федераль проекты» максатчан статьясында «- 5386F Россия Федерациясе субъектлары милкендәге аэропорт комплексларындагы объектларны реконструкцияләүне гамәлгә ашыруга, шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды акчалары исәбеннән,

финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешенең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары милкендәге аэропорт комплексларындагы объектларны реконструкцияләүне гамәлгә ашыру кысаларында дәүләт (муниципаль) милке объектларына капитал салуларны финанслашуга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 27386 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

«13 4 05 00000 Аавтомобиль, шәһәр электр транспортын үстерү» процесс чаралары комплексы» максатчан статьясының атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13 4 05 00000 «Транспорт комплексында дәүләт сәясәтен камилләштерү» процесс чаралары комплексы;

к) «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.13 пунктчасында:

«14 2 11 00000 «Авыл территорияләрен төзекләндерү» төбәк проекты» максатчан статьясының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14 2 11 00000 «Авыл халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» төбәк проекты;

«14 2 12 00000 «Авыл территорияләрен төзекләндерү» төбәк проекты» максатчан статьясының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14 2 12 00000 «Авыл территорияләренең бүгенге йөзе» төбәк проекты;

л) «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.17. пунктчасында «19 2 01 00000 «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» төбәк проекты» максатчан статьясы атамасын түбәдәге редакциядә бәян итәргә:

«19 2 01 00000 «Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәүнең нәтиҗәлелеген арттыру. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәттә кадрлар эшенә заманча технологияләр кертү»;

м) «Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.21 пунктчасында «23 2 01 00000 «Газ-мотор ягулыгы сыйфатында компримирланган табигый газны автотранспорт чараларында өстенлекле файдалану өчен шартлар тудыру» төбәк проекты» максатчан статьясына чыгымнарның түбәндәге юнәлешен өстәргә:

«- 71730 Транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерү чараларын гамәлгә ашыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерү чараларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

н) «Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.23 подпунктында 26 2 J1 00000 «Туристлык инфраструктурасын үстерү» федераль проекты» максатчан статьясына чыгымнарның түбәндәге юнәлешләрен өстәргә:

«- 55581 Туристлык инфраструктурасын үстерүгә юнәлдерелгән иҗтимагый инициативаларга дәүләт ярдәме

- 55582 Татарстан Республикасында туризмны үстерүгә юнәлдерелгән вакыйгаи чараларга ярдәм итү һәм аларны үстерүгә этәргеч бирү»;

о) «Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы 2.25 пунктчасында «30 4 01 00000 «Казан талантларның ачык университеты 2.0» автоном коммерциясез оешмасы дәүләт программасы операторы эшчәнлеген тәэмин итү» процесс чаралары комплексы» максатчан статьясының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«30 4 01 00000 «Татарстан Республикасы дәүләт программасы операторы – «Казан талантлар ачык университеты 2.0 «коммерциягә карамаган автоном оешмасы эшчәнлеген тәэмин итү» процесс чаралары комплексы;

п) «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы 2.30 пунктчасында «38 2 07 00000 «Татарстан балалары» төбәк проекты» максатчан статьясының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«38 2 07 00000 «Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре» төбәк проекты;

р) «Татарстан Республикасы бюджеты һәм Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондлары чыгымнарының программада каралмаган юнәлешләре» 2.33 пунктчасында:

«73 0 00 00000 Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондлары идарәсе эшчәнлегенең программада каралмаган юнәлешләре» максатчан статьясының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«73 0 00 00000 Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары эшчәнлегенең программага кертелмәгән юнәлешләре»;

«73 2 00 00000 Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондлары аппаратлары тарафыннан функцияләр башкару» максатчан статьясында чыгымнарның түбәндәге юнәлешен өстәргә:

«- 44020 Татарстан Республикасы архив фонды документларын һәм башка архив документларын саклауны, исәпкә алуны, туплауны һәм алардан файдалануны тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондының Татарстан Республикасы Архив фонды

документларын һәм башка архив документларын саклауны, исәпкә алуны, туплауны һәм алардан файдалануны тәэмин итүгә чыгымнары чагылдырыла.»;

«99 0 01 00000 Программага кертелмәгән чыгымнар» максатчан статьясына чыгымнарның түбәндәге юнәлешләрен өстәргә:

«- 25100 Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә җирле бюджетларга башка бюджетара трансфертлар бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның җирле бюджетларга кертү бюджетлар керемнәре классификациясенең «Бюджетларга тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар» 000 2 02 49999 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагыла.

- 25420 Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның җирле бюджетларга керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Бюджетларга тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар» 000 2 02 49999 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.

- 63990 «Иң яхшы муниципаль практика « Бөтенроссия бәйгесендә җиңүчеләрне бүләкләүгә дотацияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Иң яхшы муниципаль практика» Бөтенроссия бәйгесендә җиңүчеләрне бүләкләүгә федераль бюджеттан дотацияләр исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга дотацияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Иң яхшы муниципаль практика» Бөтенроссия бәйгесендә җиңүчеләрне бүләкләүгә бюджетларга дотацияләр «000 2 02 15399 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.».

2. 2 кушымтада:

а) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «01 2 13 R1230 | Шикәр чиреннән интегүчеләр өчен төбәк эндокринология үзәкләрен һәм мәктәпләрне төзү (үстерү) һәм җиһазландыру (өстәмә җиһазландыру) чараларын федераль бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашыру» |

түбәндәге эчтәлектәге юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «01 2 13 R1510 | Авыл халкына һәм ерак территорияләрдә яшәүчеләргә медицина ярдәме күрсәтә торган медицина оешмаларын шикәр чирен ачыклау һәм элек ачыкланган шикәр чиреннән интегүче пациентның хәлен тикшереп тору өчен җиһазландыру (яңадан җиһазландыру) чараларын гамәлгә ашыруга финанслашыла торган чыгымнар |
| 01 2 13 R1520 | Йөкле хатын-кызларны глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруга финанслашыла торган чыгымнар»; |

б) юлдан соң:

| | |
|---|---|
| «01 4 12 97170 | Сәламәтлек саклау өлкәсендә гамәли фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр» |

түбәндәге эчтәлектәге юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «01 4 12 R3870 | Генетик эксперт тикшеренүләре уздыруны федераль бюджет акчалары исәбеннән финанс белән тәэмин итү»; |

в) юлны

| | |
|---|---|
| «02 0 00 00000 | «Татарстан Республикасында мәгарифне һәм фәнне үстерү» дәүләт программасы» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «02 0 00 00000 | «Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү» дәүләт программасы»; |

г) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «02 4 01 53032 | Дәүләт гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләү» |

түбәндәге эчтәлектәге юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «02 4 01 R0500 | Татарстан Республикасы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларының, һөнәри белем бирү оешмаларының, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының балалар иҗтимагый берләшмәләре белән тәрбия һәм үзара хезмәттәшлек буенча директорлар киңәшчеләренә федераль бюджет акчалары исәбеннән ай саен акчалата түләү |
| 02 4 01 R0501 | Татарстан Республикасы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының тәрбия һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлек буенча директорлар киңәшчеләренә айлык акчалата түләү |
| 02 4 01 R0502 | Татарстан Республикасы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларының, һөнәри белем бирү оешмаларының балалар иҗтимагый берләшмәләре белән тәрбия һәм үзара хезмәттәшлек буенча директорлар киңәшчеләренә айлык акчалата түләү |
| 02 4 01 R3030 | Гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик |

| | |
|---|---|
| | хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән айлык акчалата түләү |
| 02 4 01 R3031 | Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләүләрне тәэмин итү өлешендә |
| 02 4 01 R3032 | Гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларының педагог хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләү»; |

д) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «02 4 03 53630 | Дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге (кураторлык) өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән айлык акчалата түләү» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «02 4 03 R3630 | Урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге (кураторлык) өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән айлык акчалата түләү»; |

е) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «02 4 04 43600 | Балалар һәм яшьләр өчен чаралар үткәрү» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «02 4 04 43700 | Физика-математика буенча белем бирүнең сыйфатын яхшырту чаралары комплексын гамәлгә ашыру»; |

ж) юлны

| | |
|---|---|
| «02 4 06 00000 | «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен психологик-педагогик медицина-социаль үзәкләр һәм дәүләт учреждениеләре челтәре эшчәнлеген тәэмин итү» процесс чаралары комплексы» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «02 4 06 00000 | «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен психологик-педагогик һәм медицина-социаль үзәкләр һәм дәүләт учреждениеләре челтәре эшчәнлеген тәэмин итү» процесс чаралары комплексы»; |

з) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «03 4 01 59400 | Россия Федерациясе субъектлары арасында, шулай ук Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге дәүләтләре территорияләре чикләрендә гаиләләреннән, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалардан, мәгариф оешмаларыннан һәм башка оешмалардан рөхсәтсез киткән балигъ |

булмаганнарны йөртүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен федераль бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашыру»

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

«03 4 01 60830 Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кергән затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган һәм 23 яшькә җиткән затларга төзекләндерелгән торак урын сатып алуга яисә торак урыны сатып алуга бирелгән кредитны (заемны) тулысынча түләп бетерү өчен түләүләр бирү, бу шартнамә буенча заем алучының йөкләмәсе ипотека белән тәэмин ителгән»;

и) юлны

«03 4 03 66940 Украина территориясендә, шулай ук максималь һәм уртача хәвеф куркынычы кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәүче, торак урыннарыннан китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасында вакытлыча урнашу һәм туклану пунктларында урнашкан Россия Федерациясе гражданнарын, чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыруга һәм тукландыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау)»

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«03 4 03 66940 Украина территориясендә, шулай ук максималь һәм уртача хәвеф куркынычы кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәүче, торак урыннарыннан китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасында вакытлыча урнашу һәм туклану пунктларында урнашкан (булган) Россия Федерациясе гражданнарын, чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыруга һәм тукландыруга бәйле чыгымнарны каплау»;

к) юлдан соң

«03 4 04 05084 Педагогия хезмәткәрләренә-халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт учреждениеләренең яшь белгечләренә дәүләт ярдәменең өстәмә чараларын күрсәтү»

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

«03 4 04 05089 Тормышта авыр хәлләрдә калган балаларга ярдәм күрсәтү чаралары комплексын гамәлгә ашыру»;

л) юлны

«04 2 06 60830 Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кергән затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган һәм 23 яшькә җиткән затларга төзекләндерелгән торак урын сатып алуга яисә торак урыны сатып алуга бирелгән кредитны (заемны) тулысынча түләп бетерү өчен түләүләр бирү, бу шартнамә буенча заем алучының йөкләмәсе ипотека белән тәэмин ителгән»

төшереп калдырырга;

м) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «04 2 0К 97300 | Инфраструктура проектларын федераль бюджеттан бирелә торган махсус казначылык кредиты исәбеннән гамәлгә ашыру» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «04 2 0К R688F | «Новая Портовая» гидротехник корылмасын төзү» Казан шәһәре, (1 этап) 1.1. этап» объектын гамәлгә ашыру максатларында финанслашыла торган чыгымнар, шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды акчалары исәбеннән»; |

н) юлны

| | |
|---|---|
| «05 4 01 52900 | Эшсез гражданнарга федераль бюджет акчалары исәбеннән социаль түләүләр» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «05 4 01 52900 | Эшсез гражданнарга һәм гражданнарның башка категорияләренә халыкның мәшгульлеге турындагы законнар нигезендә федераль бюджет акчалары исәбеннән социаль түләүләр»; |

о) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «07 0 00 00000 | «Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» дәүләт программасы» |

түбәндәге эчтәлектәге юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «07 2 00 00000 | Федераль (төбәк) проектлар |
| 07 2 0К 00000 | «Социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» региональ проекты |
| 07 2 0К 72310 | Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкендәге социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт»; |

п) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «08 2 А1 54561 | Төбәк һәм муниципаль Яшь тамашачы театрларын һәм курчак театрларын капиталь ремонтлау юлы белән модернизацияләү» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «08 2 А1 54562 | Төбәк һәм муниципаль Яшь тамашачы театрларын һәм курчак театрларын реконструкцияләү юлы белән модернизацияләү»; |

р) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «08 2 А1 55199 | Сәнгать төрләре буенча төбәк һәм муниципаль балалар сәнгать мәктәпләрен модернизацияләү чаралары» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «08 2 A1 55800 | Региональ һәм муниципаль театрларны реконструкцияләүгә һәм капиталь ремонтлауга финанслашыла торган чыгымнар»; |

с) юлны

| | |
|---|---|
| «11 2 06 6527A | «Экспортка ярдәм итү үзәкләре ярдәмендә товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) экспортын кече һәм урта эшкуарлык субъекты гамәлгә ашыру» чарасын гамәлгә ашыруга «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидияләр» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «11 2 06 6527A | «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенең «Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан Экспортка ярдәм үзәкләре ярдәмендә товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) экспортын гамәлгә ашыру» чарасын гамәлгә ашыруга чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидияләр»; |

т) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «13 2 02 R7690 | Дәүләти-хосусый партнерлык механизмын кулланып гамәлгә ашырыла торган проектлар буенча юл эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү максатларында финанслашыла торган чыгымнар» |

түбәндәге эчтәлектәге юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «13 2 06 00000 | «Төбәк аэропортларны үстерү» төбәк проекты |
| 13 2 06 72360 | Аэропорт комплексларында объектларны реконструкцияләү»; |

у) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «13 2 R1 53940 | Автомобиль юлларны һәм ясалма юл корылмаларын норматив хәлгә китерүгә финанслашыла торган чыгымнар» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә::

| | |
|---|---|
| «13 2 R1 5394F | Автомобиль юлларны һәм ясалма юл корылмаларын норматив хәлгә китерүгә, шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды акчалары исәбеннән финанслашыла торган чыгымнар»; |

ф) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «23 2 01 00000 | «Газ-мотор ягулыгы сыйфатында автотранспорт чараларында компримирланган табигый газдан өстенлекле файдалану өчен шартлар тудыру» төбәк проекты» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «23 2 01 71730 | Транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерү чараларын үткәрү»; |

х) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «26 2 J1 55580 | «Туризмны үстерү»Россия Федерациясе дәүләт программасы күрсәткечләренә ирешүгә бердәм субсидия кысаларында финанслашыла торган чыгымнар» |

түбәндәге эчтәлектәге юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «26 2 J1 55581 | Туристлык инфраструктурасын үстерүгә юнәлдерелгән иҗтимагый инициативаларга дәүләт ярдәме |
| 26 2 J1 55582 | Татарстан Республикасында туризмны үстерүгә юнәлдерелгән вакыйгаи чараларны гамәлгә ашыруга ярдәм итү һәм аларны үстерүгә этәргеч бирү»; |

ц) юлны

| | |
|---|---|
| «30 4 01 00000 | «Казан талантлар ачык университеты 2.0» автоном коммерциягә карамаган оешмасының дәүләт программасы операторы эшчәнлеген тәэмин итү» процесслы чаралар комплексы» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «30 4 01 00000 | «Татарстан Республикасы дәүләт программасы операторы – «Казан талантлар ачык университеты 2.0 «автоном коммерциягә карамаган оешмасы эшчәнлеген тәэмин итү» процесс чаралары комплексы»; |

ч) юлны

| | |
|---|---|
| «41 2 01 06220 | Инновацион ваучерлар кертү чараларын үткәрү» |

төшереп калдырырга;

ш) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «41 2 02 00000 | «Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсешенә этәргеч бирү инструменты буларак, инновацион ваучерларны кертү» төбәк проекты» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «41 2 02 06220 | Инновацион ваучерлар кертү чараларын үткәрү»; |

щ) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «99 0 01 22910 | Икътисадның мобилизацион әзерлеген тәэмин итү чаралары» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә::

| | |
|---|---|
| «99 0 01 25100 | Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы муниципаль оешмалары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар»; |

э) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «99 0 01 25410 | Алкоголь, наркотик яисә башка төрле токсик исерек хәлдәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә::

| | |
|---|---|
| «99 0 01 25420 | Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар»; |

ю) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «99 0 01 57010 | Җәмәгать тәртибенә һәм җәмәгать иминлегенә яный торган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү буенча тапшырылган вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруга федераль бюджетка субвенцияләр» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «99 0 01 63990 | «Иң яхшы муниципаль практика» Бөтенроссия бәйгесендә җиңүчеләрне бүләкләүгә дотацияләр»; |

я) юлны

| | |
|---|---|
| «01 4 12 05390 | Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә иминләштерелгән затларга Татарстан Республикасы медицина оешмаларына күрсәтелгән медицина ярдәме» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «01 4 12 05390 | Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә иминләштерелгән затларга Татарстан Республикасы медицина оешмалары тарафыннан күрсәтелгән медицина ярдәме»; |

я[1]) юлны

| | |
|---|---|
| «73 0 00 00000 | Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондлары идарәсе эшчәнлегенең программага кертелмәгән юнәлешләре» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «73 0 00 00000 | Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары эшчәнлегенең программага кертелмәгән юнәлешләре»; |

я[2]) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «73 2 00 00000 | Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондлары аппаратлары тарафыннан функцияләр башкару» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «73 2 00 44020 | Татарстан Республикасы Архив фонды документларын һәм башка архив документларын саклауны, исәпкә алуны, туплауны һәм алардан файдалануны тәэмин итү». |